**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский муниципальный район муниципальное образование «Мюдовское сельское поселение»**
**423063 п. Мюд, ул. Центральная д 35**
**тел. 884344 4-04-33**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы муниципаль беремлеге "Мюд авыл җирлеге"**
**423063 Мюд авылы**
**Центральная урамы, 35**
**тел. 884344 4-04-33**

КАРАР

N 5 23.04.2025 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Башкарма комитетының 24.12.2018 елгы 16 номерлы "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында һәм "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Башкарма комитетының "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 24.12.2018 ел, № 16 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 5 нче кушымтаның 1.5 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"1) гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка "Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - Бердәм портал), дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасын йә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтын гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (әгәр әлеге Федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса), тәкъдимне, гаризаны яисә шикаятьне, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгатен;

";2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru / һәм Аксубай муниципаль районы сайтында http://aksubayevo.tatar.ru. урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мюд авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Т.В. Зюзина